ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Ленина, д.1а, ,
423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Димтамак авылы, Ленин урамы, 1а
йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz @tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 21 «08» декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 16 августындагы 11 санлы карары белән расланган Димтамак авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы, 1996 елның 31 маендагы «Оборона турында»гы 61-ФЗ санлы, 1997 елның 26 февралендәге «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында»гы 31-ФЗ санлы, 1998 елның 28 мартындагы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы 53-ФЗ санлы, 2023 елның 14 апрелендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 127-ФЗ санлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау турында»гы 719 санлы карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә һәм җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге башкарма комитеты
К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 16 августындагы 11 санлы карары белән расланган Димтамак авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.3. пунктын түбәндәге редакөиядә бәян итәргә:

«1.3. Димтамак авыл җирлеге территориясендә хәрби исәпкә түбәндәгеләр алынырга тиеш:

а) хәрби исәпкә алынырга тиешле һәм запаста булмый торган 18 яшьтән 27 яшькә кадәрге ир-ат җенестәге гражданнар;

б) запаста торучы гражданнар:

запаста торучы ир-атлар;

Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запасына кертеп хәрби хезмәттән азат ителгәннәр;

запастагы офицерларны хәрби әзерләү программалары, сержантларны, запастагы старшиналарны хәрби әзерләү программалары яисә солдатларны, запастагы матросларны хәрби әзерләү программалары яисә югары белем бирү хәрби оешмаларында сержантларны, запастагы старшиналарны хәрби әзерләү программалары яисә солдатларны, запастагы матросларны хәрби әзерләү программалары буенча югары белем

бирү федераль дәүләт оешмалары каршындагы хәрби уку үзәкләрендә укуларын уңышлы тәмамлаучылар;

югары белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф оешмалары каршындагы Хәрби кафедраларда запастагы офицерларны хәрби әзерләү программалары, сержантларны, запастагы старшиналарны хәрби әзерләү программалары яки солдатларны, запастагы матросларны хәрби әзерләү программалары буенча укуларын уңышлы тәмамлаучылар;

хәрби хезмәткә чакырудан азат ителү сәбәпле хәрби хезмәттән үтмәгәннәр;

хәрби хезмәткә чакырудан кичектерүләр бирү сәбәпле хәрби хезмәттән үтмәгәннәр яки 27 яшькә җиткәч, башка сәбәпләр аркасында хәрби хезмәткә чакырылмаганнар;

хәрби хезмәттән хәрби исәпкә куелмыйча азат ителгәннәр һәм соңыннан хәрби комиссариатларда хәрби исәпкә куелганнар;

альтернатив гражданлык хезмәтен үткәннәр;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге "Хәрби исәп турында Нигезләмәне раслау турында"гы 719 санлы карарның 1 нче кушымтасы нигезендә хәрби-исәп белгечлекләре булган хатын-кызлар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов